**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«БОРДЫ» АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«01» апрель 2024 ел                                                  № 41/1

«Борды авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Советының 2022 елның 07октябрендэге 21/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнар, «Борды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. «Борды авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Советының 2022 елның 07 октябрендәге 21/3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Төзекләндерү өлкәсендә контроль предметы булып юридик затларның, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар (алга таба - контрольдәге затлар) тарафыннан Борды авыл җирлегенең төзекләндерү кагыйдәләрен (алга таба – төзекләндерү кагыйдәләре), рөхсәт документларындагы таләпләрне, Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә үтәлергә тиешле документлар таләпләрен (алга таба – мәҗбүри таләпләр), шулай ук контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларның үтәлеше тора»;

1.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда куркынычларны бәяләү һәм алар белән идарә итү системасы кулланыла.

1. Югары куркыныч категориясенә янәшәдәге территорияләр керә;

2. Уртача куркыныч категориясенә элмә такталар, биналар, корылмалар, төзелмәләр фасадлары, кече архитектур формалар, капиталь булмаган стационар

булмаган корылмалар һәм төзелмәләр, мәгълүмат щитлары, күрсәткечләр, киртәләү җайланмалары керә;

3. Түбән куркыныч категориясенә төзекләндерү өлкәсендәге барлык башка контроль объектлары керә.»;

1.3. 3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Төзекләндерү өлкәсендә контроль үткәргәндә Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелгән чаралар кысаларында түбәндәге контроль чаралар һәм контроль гамәлләр үткәрелергә мөмкин:

1) контроль сатып алу (карау, эксперимент аша);

2) мониторинглы сатып алу (карау, сораштыру, эксперимент, инструменталь тикшерү, документлар таләп итү, сынау, экспертиза аша);

3) сайлаулы контроль (карау, язма аңлатмалар алу, документлар таләп итү, пробалар (үрнәкләр) сайлап алу, инструменталь тикшерү, сынау, экспертиза аша);

4) инспекция визиты (карау, сораштыру, мәҗбүри таләпләр нигезендә контрольдәге зат (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерым структур бүлекчәләре) урнашкан урынында булырга тиешле документларны таләп итү, язма аңлатмалар алу, инструменталь тикшерү аша);

5) рейд тикшерүе (карау, тикшерү, сораштыру, язма аңлатмалар алу, документлар таләп итү, пробалар (үрнәкләр) сайлап алу, инструменталь тикшерү, сынау, экспертиза, эксперимент аша);

6) документаль тикшерү (язма аңлатмалар алу, документлар таләп итү, экспертиза аша);

7) күчмә тикшерү (карау, тикшерү, сораштыру, язма аңлатмалар алу, документлар таләп итү, пробалар (үрнәкләр) сайлап алу, инструменталь тикшерү, сынау, экспертиза, эксперимент аша).»;

1.4. Нигезләмәнең 1 кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә: «Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары булып тора:

1. Җирле үзидарә органына реклама элмә тактасын килештерү турында гариза җибәрү факты булмаганда, автомобиль транспортын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәт күрсәтү буенча контрольдәге зат тарафыннан эшчәнлек башланган көннән 90 календарь көн узу.

2. Бурычларына объектларны һәм төзекләндерү элементларын җыештыру буенча эшләрне башкару кергән оешма хезмәткәрләре санының квартал өчен узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, әлеге эшләрне башкару өчен билгеләнгән урып-җыю һәм махсус техника саны артмаган очракта, шул ук вакыт аралыгында 50 һәм аннан да күбрәк процентка кимүе (ләкин ике хезмәткәрдән ким түгел).

3. Объектларны һәм төзекләндерү элементларын җыештыру буенча эшләрне башкару бурычларына кергән оешманың хезмәт күрсәтү территориясендә травма алу белән бәйле рәвештә травматологик ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән гражданнар санының алдагы вакытның шул ук чоры белән чагыштырганда ике календарь атна дәвамында 15 һәм аннан да күбрәк процентка артуы.

30 календарь көн эчендә муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән таләпләр билгеләнгән контроль объекты торышыннан

тайпылуның төзекләндерү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре һәм закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү (зарар китерү) куркынычы турында раслаучы өч һәм аннан да күбрәк очраклары ачыклануы турында гражданнардан, оешмалардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан килгән, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән һәм (яки) кергән мәгълүматларның дөреслеген бәяләүгә юнәлтелгән чаралар нәтиҗәсендә алынган мәгълүмат булу.

5. Контрольдәге затка карата төзекләндерү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозган өчен административ җәза билгеләү турында административ хокук бозу турында эш буенча бер ел эчендә кимендә биш карар булу.

6. Торак пунктның бер административ-территориаль берәмлеге (урам, микрорайон) территориясендә травма алуга бәйле рәвештә травматологик ярдәм күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткән гражданнар санының алдагы вакытның шул ук чоры белән чагыштырганда ике календарь атна дәвамында 15 һәм аннан да күбрәк процентка артуы.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Борды авыл җирлеге Советы Рәисе Р.Н.Абдульманова